РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ГЛАВА ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

Ленина ул., д. 46, с. Тюлячи, 422080

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ

Ленин ур., 46 нчы йорт, Теләче авылы, 422080

тел. (факс): (843) 602-11-89, E-mail: telache@tatar.ru, http://tulachi.tatarstan.ru/

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**№ 11** **«22» марта 2017 г.**

2017 елның апрель-июль айларында хәрби хезмәткә чакырылырга тиешле гражданнарга медицина тикшерүен уздыру өчен медицина хезмәткәрләрен бүлеп бирү турында

«Хәрби бурыч һәм хәрби хезмәт турында» 1998 елның 28 мартындагы 53-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә гражданнар сәламәтлеген саклау нигезләре турында» 2011 елның 21 ноябрендәге 323-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Хәрби-табиб экспертизасы турындагы нигезләмәне раслау турында» 2013 елның 4 июлендәге 565 номерлы карары, Россия Федерациясе Оборона министрының «Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә төзелгән хәрби-табиб комиссияләре эшчәнлеге өчен кирәкле документлар формаларын билгеләү турында» 2015 елның 14 октябрендәге 615 номерлы приказы, «Россия Федерациясе гражданнарын хәрби хезмәткә әзерләүне медицина белән тәэмин итүне оештыру турында»Россия Федерациясе оборона Министры һәм Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының 2001 елның 23 маендагы 240/168 номерлы приказы нигезендә, 2017 елның апрель-июль айларында хәрби хезмәткә чакырылырга тиешле гражданнарга сыйфатлы медицина тикшерүе уздыру өчен

КАРАР БИРӘМ:

1. ДАССУ «Теләче үзәк хастаханәсе» баш табибына 2017 елның апрель-июль айларында хәрби хезмәткә чакырылырга тиешле гражданнарга медицина тикшерүләрен үткәрү өчен табиб-белгечләр һәм урта медицина персоналын кирәкле санда бүлеп бирүне тәкъдим итәргә.
2. Медицина комиссиясен уздыру өчен җибрелгән табиб-белгечләр һәм урта медицина персоналының уртача айлык хезмәт хакын сакларга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе Р.Р. Нуруллинга йөкләргә.

ОБЩИЙ ОТДЕЛ ГОМУМИ БҮЛЕГЕ

И.Ф. Зарипов